ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » гыйнвар 2026 ел № 70

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

“Җирләү һәм җирләү эше турындагы” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, “2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турындагы” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары, Арча районы Советының 2024 елның 22 маендагы 286 номерлы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы” карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарның 1 һәм 2 нче кушымталары буенча 9678 сум 63 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә..

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.м. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И. Ә. Галимуллин

Кушымта №2
Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы башкарма
комитеты карарына
«30» 01 2026 ел № 70

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән Исемлеге бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү (киендерү – төрү) | 348,26 |
| 3. Табут һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 6060,37 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 774,00 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2496,00 |
| Барысы | **9678,63** |

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы башкарма
комитеты карарына
«30» 01 2026 ел № 70

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән
Исемлеге бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 6408,67 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 773,96 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2496,00 |
| Барысы | **9678,63** |